**Хурлык белән сугарылган горурлык ...**
**Яки фәнгә “заманча” караш**

(Татар теленең “яңа” орфография сүзлеген кулга алгач туган фикерләр, борчылулар һәм уйланулар хакында).

Җәмгыятьтә бара торган интенсив яңарыш, техник алгарыш һәм глобальләшү процессларының телдә, бигрәк тә аның лексик катламында, үзгәрешләр китереп чыгаруы яңалык түгел. Әлеге новацияләр, һичшиксез, теркәү, кодификацияләү, аларның телдәге үзләшү дәрәҗәсен билгеләү кебек мөһим чараларны таләп итә. Бу җәһәттән төп норматив сүзлекләрнең берсе булган орфография сүзлеге үзенчәлекле урын алып тора, чөнки ул телдә кулланылган һәр сүзнең язылыш стандартын билгели, дөрес язу үрнәген, эталонын бирә.

Соңгы елларда телебез чит телдән кергән яңа сүзләр һәм кулланышка кайтарылган иске гарәп-фарсы алынмалары хисабына тагын да чуарлана төште. Бу, әлбәттә, фән, уку-укыту, радио-телевидение һәм журналистика өлкәсендә эшләүчеләрдә генә түгел, киң катлам укучыларда да канәгатьсезлек уята, язуда һәм укуда, телебезне өйрәнүдә өстәмә кыенлыклар тудыра. Шунлыктан, телебездәге соңгы еллардагы үзгәрешләрне чагылдырган, ике, өч, дүрт төрле язылышларга (чагыштыр: *газета, газет, гәзит, гәҗит* һ.б.) урын калдырмаслык бердәм фәнни фикерләрне чагылдырган, дөрес язылышка караган күп кенә мәсьәләләргә ачыклык кертүне максат итеп куйган эталон сүзлек булдыру күптән хәл итүне көткән гаять мөһим бурычка әверелде. Соңгы берничә ел эчендә бу хакта фәнни даирәләрдә дә сөйләшүләр еш кабатланды. “Түгәрәк өстәл” артында шундый фикер алышулар Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында (ТӘҺСИ) да булгалады. Очрашуларда орфографиябезгә бәйле вазгыятьнең җитдилеге, бу юнәлештә, “революция ясамыйча”, бүгеннән башкара алырдай конкрет эшләр эшләү мөмкинлеге хакында сүз булды, белгечләрдән торган төркем булдырып, татар теленең бүгенге таләпләргә җавап бирә алырдай яңа офография сүзлеген төзү, аны махсус төзелгән комиссиядә тикшереп гамәлгә кую кебек мөһим мәсьәләләр каралды. Бу эштә Институтның төп роль – башлап йөрү, ягъни координация үзәге ролен үтәр өчен зур фәнни потенциалы һәм мөмкинлекләре барлыгы турындагы фикер дә беркем өчен сәер яңгырамады. Татар теленең соңгы елларда басылган орфография сүзлеге дә, гәрчә аның дөньяга чыкканына инде дистәгә якын ел үткән булса да (Татар теленең орфография сүзлеге / Ф.Ә. Ганиев, И.И. Сабитова. – Казан: “Раннур” нәшрияты, 2002. – 432 б.), нәкъ менә шушы колективта хезмәт итүче галимнәр тарафыннан эшләнгән иде. Ләкин, төрле сәбәпләр аркасында, иң элек, күрәсең, дәүләт тарафыннан, проблеманы аңлаган хәлдә дә, нинди дер конкрет адымнар ясалмаганлыктан, Институт кысаларында гына бу эшкә алынырга җөрьәт итүчеләр табылмады. Шулай да, киң фәнни җәмәгатьчелек әлеге проблемадан читләшмәде һәм читләшми, аны хәл итү юлларын эзли. Аерым шәхесләр исә бу юнәлештә конкрет гамәлләр дә кыла.

Шуларны исәпкә алганда, Казан (Идел буе) федераль университеты (КФУ) профессоры К.Р. Галиуллин һәм Татарстан китап нәшрияты хезмәткәре Р.И. Раскуловалар тарафыннан төзелгән “Татар теленең орфографик сүзлеге”: якынча 43 000 сүз / Төз. К.Р. Галиуллин, Р.И. Раскулова. –Казан : Мәгариф, 2010. – 399 б.) (ТТОС) бик вакытлы эшләнгән дип уйларга нигез бирә кебек. Әлеге чыганак галимнәр, мөгаллимнәр, укучылар, гомумән, киң катлам кулланучылар өчен дә иң актуаль, иң көтелгән, иң кирәкле сүзлек булып торырга тиештер. Сүзлекнең редколлегиясе составына танылган тел галимнәре Татарстан Фәннәр академиясе (ТФА) академиклары М.З. Зәкиев, Р.А. Юсупов, Казан федераль университеты (КФУ) профессоры Ф.М. Хисамова, сүзлекне дөньяга чыгарган Татарстан китап нәшрияты директоры Д.С. Шакиров кергән. Хезмәтне бәяләүчеләр исемлеге дә аның җитдилеге, фәнни яктан төпле чыганак булырга тиешлегенә ишарәли: КФУның хәзерге татар теле кафедрасы (кафедра мөдире – филология фәннәре докторы доцент Г.Р. Галиуллина), ТӘһСИнең лексикография бүлеге (бүлек мөдире – филология фәннәре докторы доцент А.Ә. Тимерханов), Яр Чаллы дәүләт педагогика институты профессоры Р.С. Абдуллина.

Бу сүзлекнең ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы заказы белән эшләнгәнлеге, аның финанс ярдәме белән бастырылганлыгы мәгълүм. Ләкин хезмәтнең үзендә, ни сәбәпледер, андый очракларда һәрвакытта күрсәтелә торган министрлык исеме дә, ул хакта бернинди мәгълүмат та урын алмаган. Гомумән, монда министрлык, нәшрият һәм авторлар бер-берсен ничек табыштылар икән, дигән табигый сорау туа. Орфография сүзлеге кебек зур капиталь фәнни хезмәт эшләп чыгару алай гади генә дус-иш, әшнәләр арасында эшләрне әнә шулай гади бүлешү юлы белән генә эшләнә аламы икән?!

Мәгълүм ки, гамәлдәге законнар таләп иткәнчә, мондый очракта ачык тендер-бәйге игълан ителә. Теләк белдерүчеләр арасыннан куелган шартларны үтәгән һәм шушындый хезмәтне башкарып чыгарга һәрьяклап әзерлекле, бар мөмкинлекләре дә булган яхшылардан-яхшы эшче төркем сайлап алына. Орфография сүзлеген төзү заказына бәйле очракта да шулай эшләнгәнме-юкмы икәнлеге хакында безгә мәгълүм түгел. Һәрхәлдә, үз вакытында бу турыда мәгълүмат чараларына тиешле хәбәр җиткерелгән булса, Институт хәтле институт аны белми-ишетми кала алмас иде. Галимнәр арсыннан, бәйгедә катнашып, әлеге гаять әһәмиятле эшкә үз өлешләрен кертергә теләк белдерүчеләр дә табылмый калмас иде. Әйе, монда кем кемне алданрак тапканлыгын ачыклау киләчәккә калсын.

Беренче карашка, хезмәтне тикшерүдә, аны бәяләүдә могтәбәр галимнәр, югары уку йортлары һәм фәнни тикшеренү учреждениеләренең тулы бер коллективлары катнашуы, һичшиксез, әлеге сүзлекнең бүгенге татар орфографиясе өлкәсендә ярылып яткан хаталар, эзлексезлек, буталчыклардан котылу юнәлешендә зур өметләр уята. Һәрхәлдә, сүзлекне кулга алу белән, иң элек әнә шундый хисләр кичердек без. Дөрес, бу өлкәгә караган мәсьәләләрнең аз гына булса да асылына төшенгән кешегә, монда төзүчеләр белән бәяләүчеләрнең урыннары ялгыш алмашынмаганмы икән, дигән уй да туарга

мөмкин. Өметләребезнең акланыуы-акланмавы турында соңрак бәян итәрбез. Лексикография бүлеге исеменең хезмәтне “рәсми бәяләүчеләр” (рецензентлар) рәтендә күрсәтелеп тә, безнең, шушы бүлек хезмәткәрләренең, аны кабаттан бәяләүгә алынуыбызның сәбәбе дә ачыклана төшәр. Иң әүвәл сүзлекнең фәнни яңалыгы кызыксындыра. Алдагы фикерләребез шул хакта. Күпләрне нык борчыган мәсьәләнең асылын тулырак ачып бирү йөзеннән, уй-фикерләребезне “лирик чигенешләр” белән катнаш бәян итә барырбыз.

Теләсә кайсы лингвистик энциклопедиядә *орфогра́фия* (борынгы грек теленнән: ὀρθός — «дөрес», γράφω — «язам») сүзенә түбәндәге эчтәлектәге аңлатма китерелә: “единообразие передачи слов и грамматических форм речи на письме. Также свод правил, обеспечивающий это единообразие, и занимающийся им раздел прикладного языкознания.” (*Сөйләмгә хас грамматик формаларның һәм сүзләрнең язмада бирелешендәге бердәйлеге. Шулай ук әлеге бердәйлекне тәэмин иткән кагыйдәләр җыелмасы һәм гамәли тел белеменең шуны өйрәнә торган тармагы.* – Тәрҗемә безнеке).Димәк, орфографиянең асылын ачкан сүз – *единообразие*, ягъни *бердәйлек*. Шулай булгач, орфографиянең иҗтимагый функциясе сүзләрнең, аларның әйтелешендәге индивидуаль, диалекталь һәм башка үзенчәлекләргә яки аермаларга карамастан, бердәй язылышын тәэмин итеп, язма телдән файдалануны җайга салудан, җиңеләйтүдән гыйбарәт. Димәк, мондый төр сүзлек төзүчеләрнең үз эшләренә зур җаваплылык тоюлары гына җитми, ә аларның татар тел белеме, грамматикасы (һәм, һичшиксез, орфографиясе, орфоэпиясе) өлкәсендә югары компетенцияле белгеч булулары да сорала. Шушы юнәлештә фикеребезне дәвам итсәк, әлеге сүзлеккә карата күптөрле сораулар туа.

Беренчедән, сүзлекнең лөгатьлеге, ягъни анда кертелгән сүзләрнең исемлеге, сүзләрне сайлау принцибы. Төзүчеләрнең орфография сүзлегендә диалекталь сүзлек, яңа сүзләр, алынмалар сүзлеген, терминологик сүзлекләрне берләштерергә тырышулары бик үк аңлашылып җитми. Монда, әлбәттә, авторларның, иң элек профессор К.Р. Галиуллинның, күп еллар дәвамында эзлекле рәвештә эшләп, нигездә татар теленә мөнәсәбәтле барлык басылып чыккан сүзлекләр һәм башка шундый чыганаклар исәбенә төрле юллар, дәүләт программалары, грантлар ярдәме белән булдырылган “Татар теленең машина фонды”на урнаштырылган материалларны мулдан файдалануы күренеп тора (кара: ТТОС, 5 б.). *Май ботканы бозмас* дип, мөмкин кадәр күбрәк лексема кертү (анда 43 000 чамасысүз, өч миллионлап (!) исем формаларының ясалуы һәм язылуы китерелә) орфография сүзлегенең фәнни кыйммәтен арттыру чарасы була алмый! Сүзлекнең максатына һәм төренә карап, сүзлекчә сайлап алына. Мәгълүм ки, һәрбер җитди хезмәтнең, шул исәптән сүзлекнең дә, ахырында, бигрәк тә соңгы елларда чыкканнарында, зур лексикографик чыганаклар исемлеге китерелә. Ә әлеге сүз барган орфография сүзлегендә “әдәбият” башы белән бирелгән тыйнак исемлекнең чыганак функциясен үтәгәнлеге шик тудыра.

Икенчедән, теләсә нинди сүзлекнең төгәл принципларга нигезләнгән, башыннан ахырына кадәр эзлекле рәвештә шул принципларны саклап төзелгән булуы мәҗбүри. Орфография сүзлеге кебек норматив басмага, "сүзлекләрнең сүзлегенә", бу таләп икеләтә кагыла. Хезмәттә исә эшләрнең башкачарак торганлыгы күзгә ташлана. Мисал өчен, гап-гади нәрсә: биредә урын алган сүзләр гамәлдәге алфавит тәртибенә никадәр туры килә?

Өченчедән, басым күрсәтү – бу төр сүзлекләр өчен мәҗбүри шарт. Кызганыч, монда да төгәллек җитми. Әлеге исемлекне күпләп дәвам итәргә мөмкин булыр иде.

Хәзергә шунысын ассызыкларга кирәктер: кем тарафыннан гына эшләнмәсен, орфография сүзлеген төзү барышында һәм басмага тәкъдим итү алдыннан аны лексикография һәм орфография белгечләреннән төзелгән махсус комиссиядә тикшертеп раслату максатка ярашлы мөһим гамәл. Татар һәм төрки тел белеме өлкәсендә зур белгечләрдән тупланган мондый җитди комиссиянең карары бу сүзлекне норматив сүзлек буларак хөкүмәттә раслау өчен дә нигез була алыр иде. Шул нигездә Мәгариф һәм фән министрлыгы аны югары уку йортлары һәм мәктәпләр өчен тәкъдим итә алыр иде. Бу җәһәттән, республикабызда Татарстан Фәннәр академиясе барлыгын, аның составында 70 еллык тарихы булган Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында сүзлекләр төзү белән шөгыльләнә торган махсус лексикография бүлеге булуын да искәртергә кирәктер. Әлеге төр сүзлекләрне төзү барышында көндәлек эшләрендә нәкъ менә шушы тикшерелә торган хезмәттә чагылган бәхәсле мәсьәләләр белән һәрдаим эш иткән белгечләрнең тәҗрибәсеннән файдалану сүзлекнең фәнни сыйфатын күтәргән генә булыр иде. Телебезнең бүгенгесе һәм киләчәге өчен гаять әһәмиятле булган мондый хезмәтләр әнә шулай, төпле фәнни нигездә, татар тел белеме белгечләре, вуз һәм мәктәп укытучылары катнашында башкарылырга тиеш иде.

Ничек кенә булмасын, тәкъдим ителгән сүзлекнең авторлары татар теленең орфография сүзлеген төзү кебек гаять зур һәм җаваплы эшкә алынырга җөрьәт иткәннәр икән, аны, булдыра алганча гына түгел, ә фәнни принципларга нигезләнеп, орфография кагыйдәләрен эзлекле рәвештә чагылдырып башкарып чыгарга тиеш иделәр. Нәрсә әйтсәгез дә, дәүләт бит шактый акча сарыф иткән!

Биредә шунысын искәртеп китү урынлы булыр: әлеге сүзлекнең әзер саналган кульязмасы ТӘһСИнең лексикография бүлегенә тикшерү һәм фикер әйтү өчен "тәкъдим ителгән" иде. Һәм бер тапкыр гына да түгел.

2010 елның май айларында, сүзлек беренче тапкыр кулыбызга килеп кергәч, без – сүзлекчеләрнең – нинди хисләр кичерүен аңлатып булырмы икән? Институт җитәкчелеге, әзер (!) хезмәткә карата фикеребезне әйтеп, аңа бәяләмә язуыбызны сорады. Хезмәттә, аның авторлары буларак, хәзер инде элеккеге "Мәгариф" нәшрияты директоры, татар китап бастыру сәнгатен үстерүгә, шул рәвешле мәдәниятебезне, мәгарифебезне үстерүгә дә зур өлеш керткән шәхесМ.Х. Вәлиев, танылган тел галиме, профессор К.Р. Галиуллин һәм югарыда телгә алынган нәшрият хезмәткәре Р.И. Раскуловаларның исемнәре күрсәтелгән иде. Сүзлеккә Мәгариф һәм фән министрлыгының грифы да

урнаштырылган иде. Матур бормалы гыйбарәләрне бер урынга куеп торып, сүзлек ул вакытта караңгы урман-чытырманны хәтерләтә иде дисәк, безнеңчә, ул бер дә арттыру булмас. Мондый төр сүзлекләргә хас булмаган күп төрле "мөгезләр" белән бер үк вакытта *вазгыять – вәзгыять, зәвекъ - зәвык, сәркатип – сәркятип* һ.б. бик күп сүзләрнең берничә төрле язылышы китерелгән һәм "бу сүзләрне ничек дөрес язарга?" дигән матур сорау астында фәлән битлек исемлек тә бар иде анда. Моны орфография сүзлеге кадәр сүзлек эшләргә алынган "тәҗрибәле" белгечләр сорый! Бәяләү өчен, фәнни даирәләрдә кабул ителгәнчә, теге яки бу хезмәтнең әзер, соңгы варианты тапшырылырга тиеш ләбаса!

Шулай да сүзлек бүлектә бик ныклап, җентекләп тикшерелде, кайбер "мөгез"ләрнең монда урынлы булмаганлыгы искәртелде, мисаллар ярдәмендә һәртөрле хаталарны төзәтү юлларын күрсәтелде. "Сүзлекне бу килеш бастырырга ярамый" дигән эчтәлектәге төп нәтиҗә (ул вакытта бәяләмә язу мөмкин түгел дип табылганлыктан) беркетмәдән өземтә шәкелендә Институт җитәкчелегенә җиткерелде.

Шушы хәлләрдән соң шактый гына вакыт үтеп, көз айлары килеп җиткән.Ул вакыт эчендә "зур фән" дөньясында да әллә ниләр булып беткән икән. 2010 елның җәй айларына, ел башында ук зур каршылык-авырлыкларны җиңеп, татар орфографиясендәге хәлләрне яхшырту кебек изге ният белән, Мәгариф һәм фән министрлыгын эшнең "изгелегенә" тәмам ышандырып, "максатчан акча" юллап ала алган "Мәгариф" нәшрияты инде кыскартылган була. Дөресрәге, ул Татарстан китап нәшрияты белән кушыла. Мондый үзгәртеп корулар, ни кызганыч, сүзлеккә дә тәэсир итми калмаган: көз айларында аны икенче кат (!) тикшерүгә китергәндә, төзүче авторлар исемлегендә беренче булып күрсәтелгән элеккеге нәшрият җитәкчесе, гомумән, авторлар арасыннан төшеп калган. Үзе башкарган эшенә чын күңелдән ышанып җитмичә, аннан әллә үзе шулай җиңел генә баш тартканмы, әллә яңа хуҗаларның карары шундый булганмы – Аллаһу әгъләм (бер Аллаһы Тәгалә үзе генә белә). Мантыйкка туры китереп фикер йөрткәндә, аның урынын берләштерелгән нәшрият директоры алырга тиеш булгандыр инде. Ләкин ул, тыйнаклык күрсәтеп, үзен редколлегия исемлегенә генә кертергә ризалыгын биргән булса кирәк. Анысы да шактый зур абруй бит аның: фәндә җитди хезмәтләре белән лаеклы рәвештә танылган ике академик, бер профессор арасында нәшрият директорына редколлегия әгъзасы булып тору! Әйе, кемгәдер горурлык, ә кемгәдер чын мәгънәсендә хурлык ...

Институт җитәкчелеге кыстый торгач, бүлектә, сүзлекнең "бераз чистарган" нөсхәсен икенче кат тикшереп, аңа бәяләмә сыман кыска гына бер нәрсә әзерләргә мәҗбүр булдык. ("Эшебез тәмам беткән хәлдә", шул сүзлекнең тагын да "камилрәк" нөсхәсен кайчан алып килерләр икән дип, көтеп утыра идек шул...). Ләкин, безнең бәяләмә язуга ризалашуыбызның катгый шарты бар иде: ТӘҺСИнең исеме (лексикография бүлеген күрсәтү турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде!) биредә, бу хезмәттә, бернинди сыйфатта да чагылырга тиеш түгел иде. Без, сүзлек бары авторларның гына карашларын чагылдыра ала, шул

рәвештә генә басмага тәкъдим ителергә тиеш, дигән фикерне ассызыкладык. Һәм ул берничек тә дәүләт акчасына нәшер ителә алмый! Фән дөньясында табигый саналган тагын бер нәрсә: басылып чыкканнан соң, әлеге хезмәткә матбугат битләре аша үзебезнең профессиональ мөнәсәбәтебезне белдерү. Бу хакта Институт директоры К.М. Миңнуллин белән бүлекнең фикере уртак иде. Чынлыкта, инде дөнья күргән сүзлекнең тышлыгыннан аңлашылганча, эшләр башкачарак килеп чыккан.

Ә сүзлекнең икенче нөсхәсен тикшерүгә килгәндә, шунысы “куандырды”: без беренче нөсхәдә күрсәткән кимчелекләрнең күбесе юк ителгән. Әмма һәр биттәге хаталы сүзләрне, куелган тамгаларны санап чыгу мөмкин эш түгел, шунлыктан, без төртеп күрсәтмәгән шундый ук типтагы хаталар кала биргән. Менә сиңа татар орфографиясе! Менә сиңа белгечләр!

Ул “нәрсә” дигәннәрендә сүзлекнең әлеге дә баягы кимчелекле якларына шактый игътибар бирелсә дә, “бәяләмә” үзе, нигездә, аның язмышы белән нык кызыксынучылар өмет иткәнчә, “уңай килеп чыкты”. Шулай да, әнә, хезмәт турында беренче әйтелгән фикерләребезнең авторларга, гафу, җаваплы нәшриятка (хәер, кемнең автор, кемнең редколлегия әгъзасы, ә кемнең нәшрият эшләре өчен җаваплы икәнлеген төгәл генә аерып әйтүе дә кыен – барысы да “үзебезнекеләр” монда!) дүрт айдан соң гына барып ирешкәнлеге ачыкланды.

Бу турыда авторлар нәшрият җитәкчесе белән Институт дирекциясендә, “сез күрсәткән хаталарны төзәтеп бетердек” дип, безнең алда хисап тотып, инде “җайлырак” бәяләмә яздыру үтенечен җиткерү максаты белән оештырылган очрашудан мәгълүм булган иде. Ул тоткарлыкның сәбәбе аңлаган кешегә ап-ачык иде – ул һаман да шул ике нәшриятның кушылуы “безнең файдага булмасмы”, дигән өметкә бәйле сузылган эш. Шул ук очрашу вакытында барлык иптәшләргә без мәсьәләнең җитди һәм гаять зур җаваплы эш икәнлеген тагын бер кат аңлатырга тырыштык, ике авторның үз көчләре, белемнәре белән генә моны тиешле фәнни югарылыкта башкарып чыга алмаячаклары хакында әйттек. Шушыларны төптән аңлаган хәлдә, сүзлекне камилләштерүдә, аның сыйфатын күтәрүдә үзебезнең дә катнашырга әзер икәнлегебезне җиткердек. Ләкин ул тәкъдим “өлешкә керү омтылышы” буларак кына кабул ителде булса кирәк. Шуның белән шул.

Шулай итеп, бу килеш хезмәтне бастырырга ярамый, дигән катгый фикер белән яшәгәндә, 2010 елның декабрь башларында “Мәгариф” нәшриятының китап кибетендә әлеге сүзлекне күреп, күзләребез маңгайга сикерде. Рәсми бәяләүчеләр исемлеге арасында бүлегебезнең исемен күреп, бер мәлгә өнсез калдык.

Сүзлек басылып чыкканга бер айлап вакыт үтсә дә, Институт җитәкчелеге тарафыннан бу хакта бернинди борчылу да, уңайсызлану дигән нәрсә дә сизелмәде. Киресенчә, бүлекнең борчыла башлаганын гына көтеп торган кебек, бар да сәгате-минуты белән йөгерешә башлады. Институт директорын, янәсе, төп башына утыртучы – нәшрият җитәкчесе икән! Ә соңгысы исә үз чиратында бар гаепне “үз өстенә” алырга ашыкты. Бу турыда аның, Институт җитәкчелеге белән килештереп, бер-ике көннән ТӘҺСИдә бүлектә үткән очрашудагы

сүзләреннән ачыкланды. Очрашуның максаты бер генә иде: эшне ничек тә булса “йомып калу”, ул турыдагы мәгълүматны, ягъни шушы мәкаләне, матбугатка чыгармау.Шакиров әфәнде, “хата миннән киткән” дип (“хатаның” хакы – 2 млн. сум!), чын күңелдән безне ышандырырга тырышты. “Киләчәктә бергә эшләү юллары турында” уйлаштык, бүлекнең инде берничә ел басылмый яткан сүзлекләренә бәйле эшләрне бүгеннән башлап җибәрергә нәшриятның әзер икәнлеге, милләт язмышы, күпләрне акча харап итүе һ.б. хакында сүз куертылды. “Ошбу басмагыз матбугатка чыккан очракта, алга таба да “архивка эшләячәксез” дигәнрәк нәтиҗә дә аңлашылды әлеге ашыгыч рәвештә оештырылган сөйләшүдән. Әйтерсең лә, республикадагы китап чыгару эше бары бер кешегә генә килеп төртелә, аны дәүләт акчасына бер генә нәшрият, бер генә зат хәл итә...! Алай булган очракта да, без бераз күтәргә әзербез. Күпкә түзгәнне, азга калгач кына сабыр итәрбез анысын. “Сабыр төбе сары алтын” ди бит халык мәкале. Ләкин, иң борчыганы шул: милли фән, мәгариф, китап бастыру өлкәләрендә эшләр болайрак барса, без милли йөзебезне тәмам акчага сатып җибәрәчәкбез.

Шулай да, һәр нәрсә үз вакыты белән кадерле! Монысы – басылачак хезмәтләр хакында. Шуңа, аның ул вакыты да озак көттермәс, дип өметләнәбез. Ә урындагы җаваплы затлар, вазгыятьне дөрес аңлап, аңа гадел бәя биреп, ул вакытны аз гына ашыктырсалар, безнең бу өлкәдәге югалтуларыбыз да азрак булыр. Без моңа ихластан ышанабыз!

Шулай итеп, әлеге сүзлекне “төзүгә”, төгәлрәге, төзәтүгә катнашырга мәҗбүр ителгән бүлек белән беррәттән, шушы өлкәдә күп еллар эшләүче башка белгечләр һәм Институт, һәм нәшрият җитәкчелегенә, шулай ук министрлыктагы җаваплы затларга аны татар тел белеме, татар орфографиясе өлкәләрендә белгеч булмаган затлардан төзетеп, бастырып чыгару дәүләт акчасын җилгә очыру гына икәнлеге, бу гамәлнең фәнни яктан мәгънәсезлеге хакында һәрдаим әйтеп килде. Ләкин оешма җитәкчеләре һәм урындагы җаваплы затлар сүзлекне бастырып чыгару өчен бар көчләрен куйдылар. Инде хәзер шул ук оешмалардагы шул ук иптәшләр әлеге “файдалы” гамәлнең йөзен киң җәмәгатьчелектән ничек тә булса яшереп калдыру чараларын барлыйлар. Менә сиңа милли фән! Монысы инде бүгенге фәнгә чын “заманча” карашның бер ачык чагылышы. Кызганыч, андый караш киң тарала бара бүген. Фән түгел, ә коммерция нигезендә фәнгә пародия булдыру белән шөгыльләнә башлады күпләр. Гомумән, фән тирәсендә бөтерелүче аерым иптәшләр милли фән алдындагы “казанышлары” өчен төрле исемнәр алуны максат итеп куя, ә кайбер андый исемнәр, әлбәттә инде, шактый гына матди нигез белән дә ныгытылган. Фәнни даирәләрдә, һәрхәлдә гуманитар фәннәр өлкәсендә, андыйлар артканнан-арта гына бара бүген. Бу юнәлештә нindидер кардиналь чаралар күрелмәсә, “киртәләр” куелмаса, филология өлкәсендәге казанышларыбыз дәүләт бүлеп биргән акчага “абруйлы” конференцияләр үткәреп, аларның “”югары дәрәҗәдә оештырылганлыгы һәм зур уңыш белән үткәнлеге” хакында телевидение аша хәбәр алуга гына кайтып калу куркынычы бар.

Шушы әйткәннәрне истә тоткан хәлдә, теге “хатага” әйләнеп кайтсак, Шакиров әфәнде, “ялгышып”, Институт кадәр институтның исемен, аның структурасындагы сүзлекләр төзү белән шөгыльләнә торган махсус бүлек исемен (әйтик, ялгышып, халык авыз иҗаты бүлеге яки башка берәр шундый бүлек исеме күрсәтелгән булса, бер хәл!) шушындый фәнни эшләнеше шикле хезмәткә “ябыштырып” җибәрә ала икән, андый ялгышлыкны төзәтү чарасы да булырга тиеш! Һәм ул бар да – суд, гамәлдәге законнарда каралган җаваплылык ул! Мондый юлны сайлау, Институтның бүгенгесе һәм киләчәктәге абруе, гомумән, аның язмышы кызыксындыра икән, – җитәкчелекнең изге бурычы. Шулай да, безнең өчен нәрсәнең нәрсә икәнлеге бик ачык: Институт җитәкчесенең, иң элек үзенең үтә шәхси мәнфәгатьләрен кайгыртып эш итүе, үзенә буйсынган тулы бер бүлекнең фикерен исәпкә алмавы, аңа төкереп каравы, һәртөрле “изге максатлардан чыгып”, анда эшләүчеләрнең профессиональ ихтыярына каршы аларны кыңгыр эшләрдә катнашырга этәрүе бүлекне талауга, аны интеллектуаль көчләүгә тиң. Мондый гамәлләр бүлеккә генә түгел, Институтка да юылмаслык кара тап төшерә. Һәм ышаныч та югалырга мөмкин. Дөрес, ул ышанычның кем тарафыннан кемгә карата югаласын төгәл генә алдан ук әйтеп бетереп тә булмыйдыр әле. Әнә, Россиянең Илбашы, берни аңлатып тормастан, үзенең кул астында эшләүче бер бәндәсенә карата ышанычын югалтты да куйды. Халык сөйләвенә караганда, нигезе дә юк түгел кебек. Ә менә үзе эшләгән өлкәдә дә, гомумән, ил күләмендә дә инде шактый танылып өлгергән журналист Парфёнов, киресенчә, хакимияткә, аның тәэсирендә эшләргә мәҗбүр булган мәгълүмат чараларына карата ышанычын югалткан. Һәм бу турыда ул ачыктан-ачык бөтен илгә әйтергә җөрьәт итте. Әйе, ул хакыйкатьне күпләр алдан да белгән булып чыкты, ләкин, күрәсең, әлегә кадәр сер итеп саклаганнар яки дус-ишләренә генә сөйләп йөргәннәр. Уйланырга нигез бар! Шуңа да карамастан, әлегә беркемне дә асып куймадылар. Монысын инде илебездә, зур авырлыклар, каршылыклар белән булса да, урнаша барган демократиянең уңай бер чагылышы дип бәяләргә кирәктер.

Әйе, үзләрен һәм үзләре җаваплы булган оешманы алдаганнар, намуслы исемнәренә тап төшергән дип ышанган иптәшләргә моның киресен исбатлау беркайчан да соң түгелдер!

Сүзлек тирәсендәге һәртөрле “маҗаралар” белән артык мавыгып киттек булса кирәк. Гәрчә, укучыбызга шуларсыз дәүләт дәрәҗәсендә төптән уйланып эшләнгән әлеге “зур фәнни проектның” (алга таба башкаларының да) асылына төшенү бик кыен булыр иде. Шулай да, хәзер, әйдәгез, “борынгыдан” ни шәкелдә булуын хәтерләгән хәлдә, сүзлекнең бүгенге халәтенә күз салыйк. Югыйсә, башыннан ук сөйләшүебезнең төп максаты башкарылган зур эшкә фәнни нигездә бәя бирүдән гыйбарәт иде.

Басылып чыккан сүзлек, әлбәттә, без элек караган кульязма вариантлардан күпкә үзгәрәк. Омонимнарны (әйтелешләре бертөрле, ләкин мәгънә уртаклыгы булмаган сүзләр: *тиен* [җәнлек] – *тиен* [акча берәмлеге]), конверсия күренешен (бер төркемгә караган сүзнең икенче сүз төркеме сүзе

сыйфатында кулланылышы: *язу* [исем] – *язу* [фигыль]) бирүдә алдагы кульязмаларда төгәллек җитми иде. Шулай да, анда алар аерып күрсәтелгән иде. Ә хәзер исә омоним яисә конверсия очракларын сүзлектә плюс (+) тамгасы белән генә күрсәткәннәр, кайсы очрак булуын үзең уйлап табарга тиеш буласың (кара: ТТОС: 114, 249 бб. һ.б.). Башка орфография сүзлекләрендә омонимнар һәр сүз төркеменә туры килгән кушымча белән күрсәтелеп аерыла. Мәсәлән, кара, - рак I (төс), кара, - сы II (язу өчен) һ.б. (ТТОС, 2002, 144 б.)

Сүзлекне элеккеге кульязмалардан аерып торган тагын бер күрсәткеч – бәхәсле моментларның төшереп калдырылуы. Өченче аерма шунда ки: кульязма вариант басымнарсыз иде. Шуңа да, әзер сүзлекнең иң буталчык урыны басымнарда.

Хәзер һәр очракны аерым карап үтик. Сүзләрне сайлау принцибы "ачык" түгел, дидек. Ягъни, сүзлектә урын алырга тиешле күп сүзләр кысрыкланып, урынсызлары, киресенчә, кереп киткән. Мәсәлән, сүзлектә нигәдер сүзләрнең дөрес язылышын ачыклауда бернинди әһәмияте булмаган күп кенә грамматик формалар китерелә: *аенда, безгә, бездәге, бирелгән, бүленмәс, гөлем, гөлдәй, дигән, дигәндә, дисәнә, дилбегәсез, дөрестән, дустым, җигелмәгән, күздә, күздән, күзгә, көйгә, куа, кияүдә, урынына, уртада* һ.б. Әлеге төр сүзлектә бу формалар булырга тиеш түгел. Гадәттә, грамматик формалар нигезгә бәйле берәр үзгәлек булган очракта гына күрсәтеләләр, мәсәлән, басымның күчмәвен күрсәтергә теләсәк һ.б. (*күрѐлмәгән, күрѐнмәүчән, кү̀ктәй, тата̀рчалап*). Чөнки татар телендә басым алмый һәм басымны уздырмый торган кушымчалар бар. Болар: фигыльләрдә зат кушымчалары (*йөргә̀нмен, куйга̀нсың* һ.б.), хәбәрлек кушымчалары (*җырчы̀мын, белгѐчсең* һ.б.), сорау кушымчалары (*килдѐме, күрдѐңме* һ.б.), юклык кушымчалар (*кү̀рмә, бѐлмәгез* һ.б.), хәл фигыль кушымчалары (*я̀тканчы, кѝткәнче* һ.б.).Бу очракларда төп сүз янында грамматик формаларны күрсәтү аклана алыр иде. Башкача грамматик формалар сүзлектә күрсәтелми. Татар тел белеменең төп закончалыклары хакында хәбәрдар булган кешегә болар – гап-гади нәрсәләр.

Мондый норматив сүзлекләргә күпләп диалекталь сүзләр һәм сөйләм теле сүзләре, тупас лексика, аңлашылмый торган артык махсус терминнар, тарихи сүзләр кертү матур күренеш түгел. Мисал өчен, *айбагар, аймылыш, әпчи карчык, амбал, армай, атан, мәкә, гомункул, гусит, гумма, дагаборын, дагаборыннар* сүзләре шундыйлардан. Алардан тыш та, "артык" булган сүз-атамалар җитәрлек әле. Мәсәлән, *госстрах* – оешма исеме (рус теле кыскартылмасы); *кандил/кандиль* – икесе дә бер үк сүз, әмма икенчесе – русча вариант, димәк, бу сүзлектә килә алмый; *кыпчак-болгар, кыпчак-угыз, кыпчак-татар* – мондый сүзләрне чиксез ясарга мөмкин, бөтен синонимнарны, антонимнарны парлаштырып бетерергә була. Андыйлар һ.б.ш. сүзлеккә кертелми. *Вольта (баганасы)–Вольт* сүзеннән, аның дөресе *–вольт баганасы* булыр иде, әмма ялгызлык исем буларак, ул сүзлеккә бөтенләй кертелмәскә тиеш.*Гидроэнергия* – мондый төр энергия юк, бу сүзлектән сүзлеккә күчеп бара торган хата. *Гидроэнергетика* бар – су агымы ярдәмендә электр энергиясен җитештерү ул. *Гидрирлау* (*гидрир* сүзе дә юк гамәлдә, *гидрат* яки *гидрит+лау*

яки *гидрация+ләү), визирлау, материаллашу, легирлаштыру, легирлау* һ.б. шундый ясалышы ягыннан дөрес булмаган сүзләр татар теле өчен ят берәмлекләр. Сүзлекне рус теле аша кергән үтә махсус сүзләр (*эпонж, мегалозавр, перхлорат, пиодермия, нервюра, левулоза* һ.б.) белән чуарлау күзгә ташлана. Мәгънәсез, артык ясалма, контекстта да куллану мөмкин булмаган сүзләр күп очрый: *җәяүлек, загслы* (гадәттә, *никахлы* дибез), *кәгазьчелек, киңсу, койрыклау, кортлатылу, кәвешчелек, дәп-дәү* (*зуп-зур* дип әйтәбез), *сап-саңгырау, дәшүле* (әдәби телдә *–өндәүле*), *түбәнчелеклелек* һ.б.ш.

*Семьясыз, тәхетсез, тәэсирсез, тоемсыз, языксыз, ялсыз, яңгырсыз, һавасыз* кебек сүзләр күп кергән. *-Сыз/-сез* кушымчасы өстәп, теләсә нинди сүздән "яңа сүз" ясап, орфография һәм башка төр сүзлекләрне тагын йөзләрчә, хәтта ки меңнәрчә атамага баетып булыр иде. Мәсьәләне һәм башкарган эшеңне төптән аңлап җиткермәү түгелме бу?!

Формасы ягыннан татарча, әмма ясалышы мантыйкка сыешлы булмаган мәгънәсез сүзләр бар. Татар кушымчалары кушып, иксез-чиксез сүз ясау мөмкинлеге бар, әмма кирәкме бу? *Каптырмалану* сүзендә логика кайда? *Миссиячелек, миссияче, гаиләче, җәяүлек, керәнләү, аулаклык* сүзләрен ничек аңларга кирәк?

Сүзлеккә кергән үтә ясалма сүзләрнең берсе – *алабуталык*. Билгеле булганча, үсемлекләрне белдергән нигезләргә *-лык* кушымчасы кушылып ясалган сүзләр күп. Мисал өчен, *каенлык, җиләклек, куралык* һ.б. Бу модель яңа сүз ясауда бик продуктив булса да, ул һәр очракта да дөрес дигән сүз түгел бит әле. Билгеле бер мәгънәгә ия кушымча билгеле бер мәгънә белдергән нигезгә ялганып билгеле бер мәгънәле сүз ясый дип беләбез. Атама бирү шулай ук халыкның культурасы, дөньяны күзаллавы, кабул итү рәвеше белән дә бәйле. Бу шартлар бозылганда, логик яктан дөрес булмаган сүзләр барлыкка килә. Әйтик, халкыбызның, бигрәк тә авыл кешесенең, *алабуталык* үстерүен күз алдына китереп буламы? Бу сүзнең русчага тәрҗемәсе ничек булыр икән? Аны авторлар телебез һәм яшәешебез өчен файдалы берәмлек дип тапсалар, һичшиксез, алда эшләячәк башка сүзлекләренә дә теркәсеннәр. Ә без бу очракта сабыр итеп торабыз. Белмәссең, авыллар бетүгә таба бара, килеп чыгуы да бар алма бакчаң урынында *алабуталык*ның.

Терминнарны бирүдә дә бердәйлек күзәтелми. Мәсәлән, *беркүзәнәклеләр* бар, *күпкүзәнәклеләр* юк. *Канатаяклылар, буынтыгаяклылар* һ.б. бар, ә *йөнтәсаяклылар, күбаяклылар* һ.б. юк. Бу терминнарның бөтенесен дә кертү өчен, әз-мәз генә булса да, биология терминнарын өйрәнергә кирәк. Юк дигәндә, мәктәп дәреслекләрен караштырып чыгарга була.

Исемнәрдән ясалган *-лы/-ле* кушымчалы нисби сыйфатларның бирелеше дә нинди принципка нигезләнүе шулай ук аңлашылмый (чагыштыр: *ант – антлы, күренеш – күренешле,капилляр – капиллярлы, кәвеш – кәвешле, кашык – кашыклы* һ.б.). Шул рәвешчә барлык исемнәргә дә *-лы/-ле* кушымчасы ялгап чыгарга була. Болай эшләү – сүзлек төзү өлкәсендә наданлык дигән сүз!

*Алтынсыман, көмешсыман* сүзләренең бирелешенә карата теләк-тәкъдимнәребезне җиткергәч, авторлар алар белән мәшәкатьләнеп тормаска

уйлаганнар: төшереп кенә калдырганнар. Алар *Татар теленең аңлатмалы сүзлеге*ндә (ТТАС) (1979 - 1981) дә урын алган (кара: 21, 263, 114, 178 бб.). *Көмешсыман*– терминнар составында да, әдәби әсәрләрдә дә бик еш очрый. *Даруханә* сүзе дә сүзлектә бөтенләй юк. Авторларның алынма яисә уңышсыз сүзләрне кертеп, еш кулланыла торган актив лексиканы төшереп калдырулары сүзлекне бизиме?

Омонимнар татар теле материалларын тасвирлаган төп академик сүзлекләргә нигезләнеп күрсәтелә дип, ТТАС, Татарча-русча сүзлек (ТРС) китерелә, тик, сүзлектә китерелгән күп кенә "омоним" дип, тамга куелган сүзләр әлеге академик сүзлектә "омоним" дип бирелми. Плюс (+) тамгасы белән бирелгән *собор, сок* һ.б. бик күп сүзләрнең омоним яисә конверсияләнгән булуы да шик тудыра. Омонимнарны күрсәткәндә, үзенең кабул ителгән тәртибе бар, алар сакланмаган. Омонимнарны техник яктан бизәп, билгеләр, символлар аша гына күрсәтү отышлымы? Аны гади укучы аера аламы?

Гадәттә, китап, сүзлекләрне кулга алгач, аларның кереш өлешен укый башлыйбыз. Әлеге орфография сүзлегенең кереше, мәсәлән, татар һәм рус телләрендә язылган. Татар теленең дөрес язылышын "мәңгеләштергән" сүзлек керешенең рус телендә язылуы бераз урынсыз һәм мәгънәсезрәк булса да, аны киресенчә, уңай як дип саныйк, ди. Телебезне өйрәнергә теләүчеләр, татар телен начар аңлаучылар һ.б. өчен мәгълүмат алырга җиңелрәк булыр. Шул ук вакытта, ул керешне бик үк бизәп тормаган техник хаталар да җибәрелгән. Мисал өчен, кыскартылмалардан соң, сүз тулысынча китерелгән очракта нокта куеп тормыйбыз, ә монда һәр урында диярлек: *кара. керешне, кара. кушымтаны, кара. форзацны* һ.б. диелә.

Дөрес язылыш таләпләрен белеп бетермәү яисә аларны сүзлектә чагылдыруда системалылык сакланмау түбәндәгеләрдә чагыла: фигыль нигезе сүзнең үзгәрми торган өлеше белән тәңгәл килмәгән очракларда түгәрәк җәяләр эчендә нигез китерелде диелсә дә, сүзлекнең башыннан ахырына кадәр барлык очракта да җәяләр эчендә боерык фигыльләр генә бирелә.

Тартым формалары күрсәтелеп бетмәгән очраклар бар. Мәсәлән, *залим* сүзендә тартым кушымчасы бирелмәгән, *зәвык* сүзендә *зәвыгы* дип күрсәтелә, *зәукы* бирелми (*халык – халкы, күрек – күрке, холык – холкы* сүзләре белән чагыштырырга мөмкин).

Кайбер гарәп сүзләре дөрес транслитерацияләнмәгән. Мисал өчен, *әукат* (соңгы иҗеге калын булганлыктан, ялгана торган кушымчалар да калын булырга тиеш – *әукатлы, әукатлылыгы*), *катыйль* (чыганак телдә *т* каты түгел, *катил* шәкелендә язылырга тиеш), *бәгъзы* (чыганак телдә калын *з* булганга күрә, *ы* белән язылышы дөрес). *Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге*ндә(Казан: Иман, 1993. – 2 томда.) алар нәкъ менә шулай бирелгән дә. М.И. Мәхмүтовның белеменә, нигездә, шик белдерерлек урын юк. *Әбелхәят, хәят, гарәбият, төркият* сүзләрендә *әдәбият, нәшрият* сүзләрендәге кебек *я (йа)* калын дифтонг. Чыганак телдә ул *әлиф* белән язылган. Бу сүзләрнең барысына да калын кушымчалар гына ялгана. *Сәркятип, фидакяр, инкяр* кебек сүзләр *я* аша язылса, дөресрәк булыр иде, дигән караштан торабыз.

Генетик нигезләре төрле булган сүзләрне аерып күрсәтү шулай ук файдалы булган булыр иде, безнеңчә. Мәсәлән, *хәе́р* (исем) – *хә́ер* (модаль сүз). Чагыштыру өчен: *яңа́* (сыйфат) – *я́ңа* (рәвеш).

Кайбер матбугат чаралары *урып җыю, таныл белү* тезмәләрен ялгыш сызыкча аша язалар. Парлы сүзләр арасында тезүле бәйләнеш күзәтелә, ә бу тезмәләрдә – ияртүле бәйләнеш, алар арасында бернинди сызыкча куела алмый. Сүзлеккә шундый типтагы иярүле бәйләнешле *фәнни тикшеренү* сүзтезмәсе кереп киткән. *Аннары* сүзенең басымы дөрес күрсәтелмәгән, аңлатмалы сүзлекнең хатасын кабатлаганнар (*анна́ры* дип бирелгән).

Игътибарны әлеге сүзлеккә генә карамый торган тагын бер мөһим мәсьәләгә юнәлтәсе килә. Гадәттә, *и, е, я* хәрефләрен күргәч, машиналь рәвештә йомшак вариант кушымча өстибез. Тамырдан дөрес булмаган бу тенденция хәзер сүзлекләргә дә үтеп керде. Аеруча бу рус сүзләренә һәм кайбер гарәп алынмаларына карый. Мәсәлән, *клише, купе, кафе, реле* һ.б.ш. Элек рус орфографик сүзлекләрендә җәя эчендә "произносится "э" дип бирәләр иде аны (югыйсә, сүзлекнең беренче, төп, авторы – рус теле белгече!). Хәзер язып тормыйлар, чөнки бар кеше дә белә. Татар телендә *клишэ* дигәндәге э, гомумән, *ы* га якын, ә без йомшак кушымча ялгап маташабыз (*клишеләнү, клишеләү, клишеле*).

Сөйләм телендә ешрак күплектә кулланыла торган *гетры, шорты, гольфы, бриджи* (без болар янына *чипсы, лосины, легинсы* сүзләрен дә өстибез) сүзләренең дә орфографиясе хәл ителеп бетмәгән. Бу сүзләрнең, беренче чиратта, чыганак телдә берлек санда кулланылу-кулланылмауларын, берлек санда килгәндә, сүз сузык авазга тәмамланса, аваз төшеп калу-калмавын, аннан соң гына тартым һәм килеш кушымчалары ялгану үзенчәлеген карарга кирәк. Мәсәлән, *гетры*ның берлек саны *гетра* булса, *гольфы*ныкы – *гольф.*

Алдагы тикшерүләрдә берничә төрле языла һәм киң катлам укучыларда кыенлык, канәгатьсезлек китереп чыгараторган (*вазгыять – вәзгыять, зәвекъ – зәвык, сәркатип – сәркятип* һ.б.) сүзләрдән бик җайлы гына котылу юлы тапканнар авторлар – ике төрле язылышлы сүзнең берсен төшереп калдырганнар. Кыскасы, "сүзлекчеләрнең" бу өлкәдә белем-тәҗрибәләре җитеп бетмәгәнлекне, бердәм фикер һәм системалылык булмауны һәр мисал дәлилли.

Бер үк төрле калыпта язылырга тиешле сүзләрнең берничә вариантта бирелүе дә сүзлекнең бәясен төшерә. Чагыштыр: *муафыйк, тәүфыйк*, ләкин *фасикъ, монафикъ.* Монда, безнеңчә, күрсәтелгән сүзләр барысы да соңгы вариантлар шәкелендә язылырга тиеш, ягъни *муафикъ, тәүфикъ.*

Сүзләр белән беррәттән *прр, прр-прр, прх, пф, пыр, һә, һе, һей, һем, һи, һм, һо* кебек күпсанлы иярмнәр китерелә. Бу нинди сүз икән, дип уйлап тормас өчен, җәя эчендә иярем дип күрсәтелгән очракта аңлаешлырак булыр иде.

Тагын бер төгәлсезлек җәяләр эчендә бирелгән сүзләр белән бәйле. Сүзлекнең авторлары "түгәрәк җәяләр эчендә гадәти шрифт белән сүзтезмәләрнең компонентлары бирелә", диләр. Әмма хезмәттә бердәйлек

сакланмаган: җәяләр эчендә ирекле сүзтезмәләрнең компонентлары түгел, ә тезмә сүзләрнең компонентлары да китерелгән. Мәсәлән, *азау (теш), кабан (дуңгызы)* һ.б. Тезмә сүзләрнең компонентларын җәяләр эчендә "яшереп калдыру" дөрес түгел. Тезмә сүзләр аерым берәмлек итеп күрсәтелергә тиеш.

Инде орфография сүзлекләрендә һичшиксез куелырга, һәм дөрес (!) куелырга, укучыда бернинди дә шик уятмаска тиешле мәсьәлә – басымнарга – киңрәк тукталыйк.

Беренчедән, *-ау/-әү* гә беткән барлык сүзләрдә, *-у/-ү* авазы кыскарып, басым *-а/-ә* гә төшә. Бу исем фигыльгә генә түгел, барлык сүз төркеменә дә карый, һәм без моны үзебезнең соңгы вакытларда төзелгән сүзлекләребездә күрсәтә башладык: *азаплаُу, азаُу, алдаُу, аркаُу, асраُу, аُу, битләُү, богаُу, бозаُу, берәُү, дүртәُү* һ.б. Бу моментлар әлеге сүзлектә искә алынмаган һәм бер очракта да күрсәтелмәгән.

Икенчедән, сыйфатларда артыклык дәрәҗәсен белдергән кисәкчәләр басымны үзенә ала, ягъни энклитика күренеше күзәтелә: *а̀п-ак, а̀п-аяз, а̀п-ачык, дө̀п-дөрес, ка̀п-кайнар, кы̀п-кызыл, кы̀п-кыска* һ.б. Сүзлектә аларның берсенә дә басым куелмаган. Көчәйткеч кисәкчәләр рәвешләр алдында килеп, рәвеш дәрәҗәләре ясалганда, басым әлеге кисәкчәләргә төшә: *көпә̀-көндез, тѝз-тиз.*Бу очракта алар күрсәтелмәгәннәр.Авторларга грамматиканы яктыртуга бәйле хезмәтләрне, ачып булса да, карыйсы бар иде.

Өченчедән, ***Татар грамматикасы***нда парлы сүзләрдә төп басым беренче сүзнең соңгы иҗегенә, ә өстәмә басым икенче сүзнең ахырына төшә, дип язылган (Татар грамматикасы. – Т. 1. – М.: Инсан, Казан: Фикер. – 1998, 512 б.). Әмма аны һәрдаим истә тотмаучылар да булырга мөмкин. Шунлыктан, орфографик сүзлектә парлы сүзләрдәге төп басымны күрсәтү кирәк. Сүзлектә аларның кайбер очраклары күрсәтелгән, әмма күпчелеге - юк. Кара һәм чагыштыр: *абына̀-сөртенә, абына̀-егыла, ава̀р-аумас, ава̀-түнә, бата̀-чума, бәла̀-каза, бәрелә̀-сугыла, бермә̀-бер, берсѐ-бер, боры̀н-борыннан, бөгелә̀-сыгыла, буйда̀н-буйга, булы̀р-булмас, буынна̀н-буынга, вата̀-җимерә, елда̀н-ел, егыла̀-тора, ѝл-көн, ѝл-күрше, ѝр-ат* һ.б.

Дүртенчедән, шул ук кагыйдә кушма сүзләргә дә кагыла: *ѝлкүләм, ку̀лалмаш, ку̀лтамга, ку̀лтаяк, кызы̀лканат, кызы̀лкүз, у̀ткойрык, уртакул*һ.б.

Бишенчедән, беренче компоненты *бер* сүзе булган кушма сүзләрдә дә басым беренче сүзгә төшә: *бѐрбөтен, бѐрбуынлы, бѐркатлы, бѐркөе, бѐртип, бѐртуган* һ.б. Сүзлектә ул күпмедер күрсәтелгән, әмма тулысынча түгел, әйтелгән сүзләрдә басым юк. *Куп* сүзе белән дә шулай: *ку̀ппочмак, ку̀псанлы, ку̀псүзле* һ.б.

Алтынчыдан, *-дай, -дәй, -тай, -тәй* кушымчаларының басымны алу-алмавы төрле хезмәтләрдә, төрле авторларда төрлечә күрсәтелгән һәм һәр икесе дә, кызганыч, норма дип тәкъдим ителә. Ә әлеге орфография сүзлегендә бу мәсьәләдә эзлеклелек юк, басым кайберләренә куелган, кайберләренә юк: *айгы̀рдай, әкияттәгедәй, булырдай.* Сүзлек төзүчеләрнең фикере буталган, дөресрәге, алар моны белмиләр булып чыга. Төгәл хәл ителмәгән очрак

буларак, мондый сүзләрдә ике басым күрсәтү дөресрәк булыр иде, чөнки ике очрак та хата түгел.

Җиденчедән, басымнарның күчү очрагын күрсәтү дә отышлы булыр иде, телебезне өйрәнүчеләргә ул аермачык күренеп торыр иде. Билгеле булганча, сүз басымы ахыргы иҗектә булган сүзләрдә, кушымча ялганган саен, басым кушымчага күчә бара. Сүзлектә, нигездә, тартым кушымчалары китерелә, ләкин басым күчеше күрсәтелми.

Санау интонациясен биргәндә саннарда норматив басым беренче иҗеккә төшә: *ѝке, а̀лты, җѝде, сѝгез, тӱгыз* һ.б. Мондый моментларны да искәртү кирәк түгелме икән?

Сигезенчедән, басымның урыны дөрес күрсәтелмәгән һәм басым бөтенләй куелмаган сүзләр дә шактый: *авиашду, әссәламегалә̀йкем, вәгаләйкемәссәлам, гә̀мумән* (чагыштыр: м*ә̀сәлән*), *ә̀стәгъфирулла, бигаӗбә, борь̀нча, га̀йре, ду̀станә, нѝсбәтән, бердә̀нбер, тә̀мам* (*һа̀ман, хә̀зер, ба̀йтак* кебекһ.б. шундый ук рәвешләр белән чагыштырып булыр иде).

Алда санап үтелгән кайбер кимчелекләрдән тыш, орфография сүзлегендә урын алырга тиешле булган башка бәхәсле моментлар да бар иде әле. Безнең бүлеккә аерым исемлек белән китерелгән иде алар. Әмма сүзлек авторлары аларны урап узудан ары чара тапмаганнар.

Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы торак пунктларының исемнәрен китерүнең максаты нидә? Ул “Татарстан Республикасындагы торак пунктлар исемнәре” һәм “Названия населенных пунктов Республики Татарстан” дип ике телдә бирелә, әмма эчтәлегендә авыл исеме, нигездә, я татарча, я русча китерелә, ягъни татарчалы-русчалы катнаш эшләнгән. Кызганыч, монда күп кенә авыл исемнәре кертелмәгән. Ул нигездә элекке чыккан шундый исемлекне күчереп алуга гына кайтып кала дигән сүз бу. Әлеге исемлек, барлык торак пунктларның исемнәрен дә кертеп, максатка ярашлы дип табылган очракларда аларның русчасын татарчага, татарчасын русчага тәрҗемә итеп (күп кеше өчен нәкъ шунысы кыенлык тудыра) эшләнгән хәлдә бик отышлы, файдалы булыр иде, дигән идек. Әмма фикеребезгә колак салмаганнар, аның болай да бик кирәкле һәм әһәмиятле кушымта буласына ышанганнар, күрәсең.

Яңа гына табадан төшкән сүзлекнең әлегә кадәр булган орфография сүзлекләреннән аерып торган “мөгез”ләре аның төрле символлар, шифрлар белән шыплап тутырылган булуы. Мисал өчен, сүзлекнең кушымта өлешен ачып карарга мөмкин (кара: ТТОС, 2010: 356-357 бб.).Гади кулланучы өчен генә түгел, ә бәлки аерым очракларда белгечләр өчен дә җиңел генә аңлашылмый торган бу “үзгәлек” орфография сүзлегеннән файдалануны җиңеләйтәме, әллә киресенчә, кыенлаштырамы? Мондый риторик сораулар бик күп.

Инде килеп, сүзлекнең библиография өлешенә (авторлар аны тыйнак кына “әдәбият” дип атаганнар, дидек) күз салсак, әлеге зур хезмәтне төзү барышында кулланылырга һәм аның ахырында күрсәтелергә тиешле күп кенә хезмәтләрне, сүзлекләрне күреп сөенә алмадык. Сүзлек төзүчеләр

лексикографик чыганакларны киң итеп күрсәтү хакындагы элек әйтелә килгән киңәшебезгә бөтенләй колак салмаганнар. "Әдәбият" дигән баш астында бирелеп, 27 пункттан торган исемлектә кайбер сүзлекләр һәм теоретик хезмәтләр кергән, әмма аларның да кайберләре рус теленә карый әле. Гомумән, теоретик хезмәтләр һәм авторлар нинди принцип белән сайланган? Мәсәлән, Х.Х. Сәлимовның бердәнбер бик кечкенә сүзлекчәсе генә күрсәтелгән, ә теоретик хезмәтләренең берсе дә юк. Татар орфографиясенең патриархы саналган Х.Р. Курбатов бөтенләй телгә алынмаган. Орфография, орфоэпия мәсьәләләрен тикшерүгә багышланган күп кенә хезмәтләр язган, махсус шул өлкә белгечләре булган башка галимнәрнең фамилияләре дә читтә калган.

Күренә ки: төзүчеләр татар теленең тулы, системалаштырылган сүзлеген булдыруны максат итеп куйсалар да, ул максатка ирешүдән бик ерак торалар. Без күрсәткән хаталарның күбесен төзәткән хәлдә, күрсәтелмәгәннәренең һәм төзәтелмәгәннәренең дә бихисап булуын бераз күзаллап, алар, "татар орфографиясендәге катлаулы мәсьәләләрнең хәл ителеп бетмәгәнлеген" аңлап (менә ачыш!), ул турыда сүзлекнең кереш өлешендә үк искәртеп, үз өсләреннән җаваплылыкны төшерүне кирәк дип санаганнар.

Югары уку йортлары программасы дәрәҗәсендә инде күптән хәл ителгән һәм студентларга укытыла торган татар тел гыйлеменә йөз чөереп төзелгән бу орфография сүзлеге татар теле орфографиясендә бер адым алга китеш буламы, әллә арткамы?!

Ничек кенә булмасын, авторлар, булдыра алганча, үз эшләрен башкарып чыкканнар. Ә менә хезмәтнең "уңышына" үзләреннән "лаеклы" өлеш керткән мөхтәрәм һәм могтәбар "редколлегия" әгъзаларының хәзерге татар орфографиясе мәсьәләләренә карашлары нидән гыйбарәт икәнлеген әлеге хезмәт битләреннән генә төшенеп җитеп булмады. Ул карашлар шактый тирән яшеренгән булса кирәк. Мөхтәрәм җәмәгать, хезмәткә бәя биргән академик-профессорларыбыз шушындый ярылып яткан гап-гади кимчелекләрне ничек күрми калганнар икән?! Әллә күреп тә, зур кыюлык күрсәтеп, гаять җаваплы эшкә алынган төзүчеләрнең, алар янында "сүзлек басылып чыксын", "килгән акчаны кире җибәреп әрәм итмәскә дип", өзелеп, җанын атып торган нәшрият җитәкчесенең күңелләрен төшермәскә булганнармы? Нәрсә әйтсәң дә, сүзлекне әзерләүгә мөнәсәбәтле һәр иптәш мәсьәләнең катлаулылыгын аңлап эш иткән ләбаса, "адымы" да ясалган, ясалмаган түгел! Иманыбыз камил: ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы яки татар орфографиясенең торышы өчен нык борчылган башка берәр министрлыкмы, яисә аның министрымы, ел саен үз бюджетыннан 2 (!) миллион сум күләмендә дәүләт акчасын чыгарып салып торса, ул акчаны "әрәм-шәрәмгә" тотмыйча, "файдалы эшкә" сарыф итәргә атлыгып торган дәүләт нәшрияты да табылыр иде (мәгәр, ул бар инде, бердән-бер, кадерле!). Шул нәшрияттан әллә кайда ерак китмичә генә, андый сүзлекне эшләргә алынырга әзер торучыларын да юлларга булыр иде әле. Шулай итеп, бер ун ел эчендә әллә никадәр әнә шундый "файдалы" адымнар ясап, без төп максатка – "гаять мөһим һәм катлаулы мәсьәлә"дән саналган "Татар теленең тулы, системалаштырылган орфографик сүзлеген булдыру"га (кара: ТТОС, 2010: 6) –

тәмам якынлашыр идек тә, җиң сызганып, бар нәшриятларның орфография мәсьәләләрен хәл итүдә тупланган тәҗрибәләрен һәм шул тәҗрибәне, китап-әдәбият укып, таныш-белешләрдән сорашып, Фәннәр академиясендәгеләргә “фикер әйттереп”, бар чыккан сүзлекләрдәге сүзләрне мәрҗән бөртегедәй түкми-чәчми җыеп, теркәп барган иптәшләр ярдәме белән төп, чын, гаять кирәкле эшкә – ОРФОГРАФИЯ сүзлеген төзергә алыныр идек. “Алыныр идек” дигәннән, без – бу мәкалә авторлары – әлбәттә, “бәяләүчеләр” сыйфатында гына инде. Ләкин бу очракта бер министрлык та 2 миллион акча белән генә, зур тырышлык күрсәтеп “бай тәҗрибә туплаганнарны” алдап, аларга эш эшләтә алмас. Чөнки аны төзү мәсьәләсе, ягъни мәсәлән орфография сүзлеген, “киң катлам белгечләр тырышлыгы белән хәл ителергә тиеш” (кара: ТТОС, 2010: 6). Димәк, монысында, басылып чыкканында, белгечләрнең әлегә “тар катламы” гына чагылган! (редколлегия әгъзаларын, бәяләүчеләрне кара). Ә югары уку йортлары профессорлары, мәшһүр академикларбызга, бер очтан Фәннәр академиясе структурасындагы махсус институтка да, аның җитәкчелеге белән “уртак тел” тапканда, киләсе гасырларга җитәчәк даны чыккан хезмәтне бәяләү кебек мактаулы да, “саваплы” да бурыч үтәүне йөкләрләр! Табылмас дисезме телебез, бигрәк тә аның ОРФОГРАФИЯСЕ өчен җаннарын да кызганмаган “җанатарлар”?! Табылыр! Ничек кенә әле ...

Сүзлекнең эчтәлеге хакында шактый күп фикерләр әйтелде, ә менә аның тышлыгына бәйле тәэсирләребез белән уртаклашырга онытыла язган бит! Шундый мәртәбәле нәшриятта сүзлек кадәр сүзлек басылып чыккан икән, ул ягы да игътибарны җәлеп итми калмый. Еш кына әле нәкъ менә шул тышлыгына, кабына кызыгып алабыз бит ашамлыгын да, китабын да, башкасын да. Хәтта гомерлек юлдашыбызны, телибезме, юкмы, әнә шул тышкы матурлык, тышкы гүзәллеккә алданып сайларга омтылабыз түгелме соң?! Сүзлеккә килгәндә, аның ул “яклары” – бар да тәртиптә кебек: зәңгәр төстәге сыйфатлы кәгазьдән эшләнгән тышлык, тышлыкка алтын хәрефләр белән төшерелгән сүзлекнең исеме, эчке өлешендә һәртөрле кушымталар тутырып бизәлгән таблицалар һ.б. Кыскасы, җисеме исеменә туры килә, дип кенә әйтәсе кала... Алданрак әйткәннәрне исәпкә алмаганда. Ләкин, рус халык мәкале нәрсә ди: “Встречают по одёжке, провожают по уму”. Әйе, бу очракта шунысын истә тотып эш итү дөресрәк булыр. Акчагыз да янга калыр!

Сүзлекнең бүгенге заманда исең китәрлек тираж – 25 000 данә белән басылып чыгуын да әйтеп үтәргә кирәктер. Яхшы тираж!!! Чагыштыр: *Татарча-русча сүзлек: 2 томда* (Казан: Мәгариф, 2007) – 5 000 данә, *Татар теленең зур диалектологик сүзлеге* (Казан: Татар. кит. нәшр., 2009) – 1 000 данә һ.б. Шулай да, тиражы белән “яңа” хезмәт профессор Ф.Ә. Ганиев һәм филология фәннәре кандидаты И.И. Сабитовалар эшләп чыгарган орфография сүзлегеннән калыша(кара:Татар теленең орфография сүзлеге. – Казан: “Раннур” нәшр., 2002. – 432 б.). Ул 50 000 данәдә басылып чыккан иде. Шунлыктан, аны бүген дә китап кибетләреннән иркенләп сатып алырга мөмкин. Ә менә тиражы белән генә түгел, эчтәлеге, фәнни сыйфаты ягыннан да йомшак сүзлекнең,

дөресрәге, гамәлдәгеләренең remake вариантының язмышы ничек булыр – вакыт күрсәтер.

Мәгариф министрлыгы “тырышлыгы” белән чыгарылганлыктан, андый зур тиражлы “кыйммәтле чыганак” республикабызның һәр мәктәп китапханәсендә булырга тиештер бит?! Ярый, алдылар ди. Шуннан, аның белән нишлиләр ди инде? (Дөрес, халкыбызның тапкыр ул-кызлары, озак уйланып, баш ватмаслар, аның да файдасын тиз табарлар!). Сүзлектә бит яңа орфография кагыйдәләрен “моннан соң исәпкә алып эш итәргә!”, дигән урыны юк. Димәк, нидән гыйбарәт инде әлеге хезмәтнең фәнни кыйммәте?!

Мәгариф министрлыгы, үз бюджетыннан шактый акча сарыф итсә дә, хезмәтне рәсми төстә закон югарылыгына күтәреп тәкъдим итүдән ничектер читләшкән булып чыга. Гомумән, министрлык ярдәме белән басылып чыккан уку-укыту әсбаплары һәм башка төрле басмаларда аның исеме (грифы) күрсәтелә торган иде. Бәяләмә сорап та, Институт җитәкчелегенә авторлар белән нәшрият җитәкчесе түгел, ә иң элек министрлыктан шундый эчтәлектәге рәсми хат килә торган иде. Ул, табигый ки, мөстәкыйль һәм барлык кызыксынган якларга бәйсез рәвештә эшләнергә тиешле. Рәсми хаты булгач, аңа җавап итеп, вакыты, авторлары күрсәтелгән һәм тиешле таләпләргә туры китереп эшләнгән бәяләмә шәкелендәге документы да булырга тиеш. Биредә, сүзлектә, ләм-мим бер сүз! Хәер, аны чыгару гына түгел, шул ук дәүләт акчасына, ягъни сезнең белән безнең – салым түләүчеләрнең – акчасына, мәктәпләргә дип, сатып алдыртып тарату чарасы да юк түгел бит әле! Әйе, уйлап, икътисад законнарын аңлап эш иткәндә, *куян шулпасының шулпасы* белән шактый халыкның тамагын туйдырырга була икәнлегенә ышанмастан ышандырырлар!

Әлеге сүзлек хакында әйтелгәннәргә йомгак бер генә, һәм ул хакыйкатьне беркем дә инкяр итә алмый: хакимияттәге аерым түрәләр, телгә алынган оешма җитәкчеләре һәм эшне башкаручыларның “максатчан тырышлыгы” белән дәүләтнең, төгәлрәге, Мәгариф һәм фән министрлыгының 2 (!) млн. сум күләмендә акчасы “җилгә очырылган”. Шулай икән, димәк, җаваплы затлар, һичшиксез, җавапка тартылырга тиеш ...!?

Ә сүзлекне төзүчеләрнең бу өлкәдә тәҗрибәләре генә түгел, белемнәре дә җитешеп бетмәгәнлеге ачык чагыла. Әйе, һәр эшнең үз остасы бар!

Республиканың спорт, сәнәгать (газ, нефть химиясе һ.б.) тармаклары янында болай да очын-очка ялгап барган милли фән, мәгариф, мәдәният юнәлешләрен үстерү өчен бүлеп бирелгән акчаны әнә шулай, “төптән уйлап, киләчәккә карап, әрәм итмичә”, тиешле күләмдә һәм тиешле урыннарга урнаштыра барсак, эшләр мөшкел! Валлаһи, мөшкел! Республикабызның 2011 елга кабул ителгән бюджетыннан аңлашылганча, ул акчаның күләме тагын да кимергә торганда, урындагы затларның ихтыяры җитеп, үз вазифаларын башкаруга җаваплырак, намуслырак якын килгәндә, шул булганын да күпкә нәтиҗәлерәк һәм файдалырак итеп кулланып булмас идемени?!

90 нчы еллар башыннан алып бүгенгәчә республикада татар телен гамәлгә кую максатында төрле юнәлештә һәм төрле дәрәҗәдә байтак күләмдә

акчалар тотылды. Әйе, эшләнгән эшләрнең нәтиҗәләре күргән күзгә күрмәслек түгел: алар күпьяклы, күптөрле, күпкырлы. Күңелдә инде пыскып утыруга гына калган миллилек учагын вакыт-вакыт дөрләтеп кабызып җибәргән сәяси карарлар кабул ителде, шулар артыннан кыю адымнар да ясалгаланды. Ләкин, максатлар дөрес һәм мулдан билгеләнеп, аларны тормышка ашыру өчен җитди хокукый җирлек һәм финанс нигезе булдырылса да, тиешле дәүләт идарәсе органнары тарафыннан төрле уку-укыту учреждениеләренә, фәнни һәм фәнни булмаган оешмалар, аерым коллективлар, галимнәргә максатчан бүлеп бирелгән акчаның урыннарга барып җиту-җитмәвен, никадәр күләмдә барып ирешүен, аның кайсы өлешенең нәрсәгә сарыф ителгәнлеген, ахыр чиктә, күз уңында тотылган нәтиҗәләрнең нидән гыйбарәт икәнлеген тикшереп тору һәм, законны бозган очракларда (акчаны башка максатларга тоту, эшне “кәгазьдә генә башкару” һ.б., һ.б.), аларны вакытында ачыклап, җаваплы затларга карата тиешле чаралар күрү кебек гап-гади гамәлләр, кызганыч, игътибар үзәгеннән төшеп кала бирә. Югыйсә, бирдеңме – вакытында сорап ала бел генә бит инде! Әллә ялгышабызмы?!Яки беркатлылыкмы бу?!

**Әлеге мәкалә Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнде һәмаларның бердәм уртак карашын чагылдыра.**

А.Ә. Тимерханов,ТӘҺСИнең лексикография бүлеге
мөдире, филология фәннәре докторы